СОВЕТ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

16 август 2018 ел г.Мензелинск № 6

**Вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү тәртибе турында**

Россия Федерациясенең Хезмәт кодексы, 2003 елның 6 октябрендә кабул ителгән "Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыру принциплары турында"гы №131-ФЗ, 2008 елның 25 декабрендә кабул ителгән "Коррупциягә каршы тору турында"гы №273-ФЗ Федераль законнары, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Уставы нигезендә Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район Советы карар чыгарды:

1. Вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү Тәртибен расларга (Кушымта).

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органнарына:

2.1.ведомствога караган оешма (учреждение) җитәкчеләрен гамәлдәге карар белән таныштырырга;

2.2.җирле үзидарә органнары ведомствосына караган оешма (учреждение) уставларына, шулай ук аларның җитәкчеләре белән төзелгән хезмәт килешүләренә вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында җирле үзидарә органы җитәкчесенә ведомствога караган оешма җитәкчесенә вазифа йөкләнүен җирле үзидарә органы җитәкчесенә хәбәр итәргә.

3.Гамәлдәге карар рәсми төстә басылырга тиеш.

4. Гамәлдәге карарның үтәлешен контрольгә алуны Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль район башлыгы урынбасары К.Р.Нәҗмиевка йөкләргә.

Минзәлә муниципаль район
Советы рәисе А.Ф. Салахов.

Татарстан
Республикасы
Минзәлә
муниципаль район
Советы карарына
кушымта
_______ 2018 ел.
№ ___

**Вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү Тәртибе**

1. Гамәлдәге Тәртип вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү процедурасын регламентлаштыра.
2. Гамәлдәге Тәртиптә мәнфәгатьләр каршылыгы буларак вазифа башкаручы затның (мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар кабул итү аның вазифаларына кергән очракта) шәхси кызыксынуы (турыдан-туры яки турыдан-туры булмаган) аның вазифаи (хезмәт) бурычларын (вәкаләтләрен башкару), тиешле йөкләмәләрен объектив, гадел үтәвенә тәэсир итә яисә тәэсир итү куркынычы булган ситуация күздә тотыла.
3. Татарстан Республикасы *Минзәлә* муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесе Россия Федерациясенең коррупциягә каршы тору турындагы законнары һәм оешманың (учреждение) уставы нигезендә мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгуы турында хәбәр итәргә, шулай ук мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм җайга салу буенча чаралар күрергә тиеш.

4. Татарстан Республикасы *Минзәлә* муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесе мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) бу турыда билгеле булган көннең икенче эш көненнән дә соңармыйча хәбәр итәргә тиеш

5. Вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында ведомствога караган оешма (учреждение) җитәкчесенә бәйле булмаган сәбәп белән гамәлдәге Тәртипнең 4 пунктында күрсәтелгәнчә хәбәр итү мөмкин булмаган очракта, белдерү кәгазе кимчелек бетерелгәннән соң бер эш

көненнән дә соңармыйча тапшырыла.

6. Хәбәр язмача формада вазифаи бурычларны үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында белдерү кәгазе рәвешендә (алга таба – белдерү кәгазе) рәсмиләштерелә.

Белдерү кәгазендә түбәндәге мәгълүматлар күрсәтелә:

а) белдерү кәгазен тутырган ведомствога караган оешма җитәкчесенең исем-фамилиясе, атасының исеме, башкарган вазифасы;

б) ведомствога караган оешма җитәкчесенең шәхси кызыксынуы йөкләнгән вазифаларны тиешенчә, объектив һәм төгәл үтәвенә тәэсир итүе (турыдан-туры яисә турыдан-туры булмаган) яисә тәэсир итү куркынычы туган вәзгыятьне тасвирлап бирү;

в) ведомствога караган оешма җитәкчесенең йөкләнгән вазифаларны тиешенчә үтәвенә тәэсир итүче яисә тәэсир итү куркынычы тудырырлык шәхси кызыксынуын квалификациялүче билгеләр (акча, башка мөлкәт рәвешендә керем алу, шул исәптән, ведомствога караган оешма җитәкчесе һәм (яки) аның белән якын туганлык мөнәсәбәтләрендә яисә шулай саналган затлар (ата-аналар, ир белән хатын, балалар, абый-эне, апа-сеңел, шулай ук ир белән хатынның ир-ат һәм хатын-кыз туганнары, балалары, балаларының ирләре), ведомствога караган оешма җитәкчесе һәм (яки) аның белән якын туганлык мөнәсәбәтләрендә торган затлар мөлкәт, корпоратив һәм башка якын мөнәсәбәтләр белән бәйле гражданнар һәм оешмалар, мөлкәткә хокуклар, мөлкәт характерындагы хезмәтләр;

г) башкарып чыгуга шәхси кызыксынучанлык тискәре йогынты ясаган яки тискәре йогынты ясау куркынычы булган вазифаи бурычларны тасвирлау;

д) мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу куркынычын булдырмый калдырырдай яисә килеп туган мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салырдай мөмкин булган тәкъдим чаралары;

е) белдерү кәгазен тутыру датасы;

ж) белдерү кәгазен тутыручы затның имзасы.

7. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесе эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) №1 Кушымтасындагы форма нигезендә төзелгән белдерү кәгазен җибәрә.

8. Эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиле) килгән белдерү кәгазьләре Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының хезмәт (вазифа башкарганда) үз-үзеңне тоту һәм мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу таләпләрен үтәү буенча Комиссиягә (алга таба – Комиссия) тикшерү өчен җибәрелә.

9. Белдерү кәгазьләрен теркәү Комиссия сәркатибе тарафыннан, тәкъдим ителгән үрнәге гамәлдәге Тәртипнең №2 кушымтасында каралганча, белдерү кәгазьләрен теркәү журналында башкарыла.

Комиссия сәркатибе белдерү кәгазендәге мәгълүматның конфиденциальлеген сакларга тиеш. Конфиденциаль мәгълүматны таратуда

гаепле зат Россия Федерациясе законнары нигезендә дисциплинар, башкача җаваплылыкка тартыла.

10. Белдерү кәгазенең теркәлү турында билге куелган күчермәсе Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма җитәкчесенә белдерү кәгазьләрен теркәү журналында имза куелып, кулга тапшырыла яисә почта аша алу турында белдерү кәгазе белән җибәрелә.

11. Белдерү кәгазьләрен алдан карап чыгу барышында Комиссия белдерү кәгазьләрен җибәргән затлардан аларда бәян ителгән хәл буенча билгеләнгән тәртиптә аңлатма алырга һәм запросларны дәүләт хакимиятенең федераль органнарына, Россия Федерациясе субъектларының дәүләт хакимияте органнарына, җирле үзидарә органнарына һәм кызыксынучы оешмаларга билгеләнгән тәртиптә җибәрелә.

12. Белдерү кәгазьләрен алдан карап чыгу нәтиҗәләре буенча аларның һәркайсына дәлилле нәтиҗәләр әзерләнә.

Белдерү кәгазьләрен алдан карап чыгу барышында алынган белдерү кәгазьләре, йомгаклау һәм башка материаллар белдерү кәгазьләре кергәннән соң җиде эш көне дәвамында Комиссия утырышына тапшырыла.

Гамәлдәге Тәртипнең 11 пунктында күрсәтелгәнчә запрослар җибәрелгән очракта, белдерү кәгазьләре, йомгаклау һәм башка материаллар эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) белдерү кәгазьләре кергәннән соң 45 көн эчендә Комиссиягә тапшырыла. Күрсәтелгән срок озынайтылырга мөмкин , әмма 30 көннән дә күпкә түгел.

13. Комиссия белдерү кәгазьләрен карый һәм алар буенча Татарстан Республикасының Минзәлә муниципаль район Советының__________ кабул ителгән № ___ “_______” карары белән расланган Комиссия турындагы Положениедә билгеләнгән тәртиптә карар кабул итә һәм кабул ителгән карарны эш бирүчегә (эш бирүченең вәкиленә) җибәрә.

14. Эш бирүче (эш бирүченең вәкиле) Комиссия караган белдерү кәгазьләре нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

а) белдерү кәгазьләрен җибәргән затның вазифаи бурычларын үтәгәндә мәнфәгатьләр каршылыгы булмавын танырга;

б) белдерү кәгазьләрен җибәргән затның вазифаи бурычларын үтәгәндә шәхси кызыксынуы мәнфәгатьләр каршылыгына китерә яисә мәнфәгатьләр каршылыгына китерергә мөмкин булуын танырга;

в) белдерү кәгазе җибәргән зат тарафыннан мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча чараларның үтәлмәвен танырга.

15. Гамәлдәге Тәртипнең 14 пункты “б” подпунктында каралганча карар кабул ителгән очракта, Россия Федерациясе законнары нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесе мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау һәм (яки) мәнфәгатьләр каршылыгын җайга салу буенча чаралар күрә.

16. Гамәлдәге Тәртипнең 14 пункты “в” подпунктында каралганча карар

кабул ителгән очракта, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенә карата Россия Федерациясенең Хезмәт кодексында, җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) уставында һәм хезмәт килешүендә каралганча, дисциплинар җәза каралган.

Белдерү кәгазен карау белән бәйле белдерү кәгазьләре һәм башка материаллар Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең личное делосына кертеләләр.

Кушымта №1
вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү Тәртибенә

_______________________________________

Татарстан Республикасы _______ вәкиллекле орган рәисенә, муниципаль район башкарма комитеты җитәкчесенә ____________ муниципаль районы Татарстан Республикасы) (сайлап алырга)

_______________________________________

(Ф.И.О.)

________________________________________

(Ф.И.О., вазифасы)

вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында

**БЕЛДЕРҮ КӘГАЗЕ**

Вазифаи бурычларны башкарганда үземдә мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яисә китерү куркынычы булган шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында хәбәр итәм (сайлап астына сызарга)

Шәхси кызыксыну килеп чыгуга нигез булып торучы хәлләр:
_______________________________________________________________

Башкару өчен шәхси кызыксыну тәэсир итә яисә тәэсир итәргә мөмкин булган вазифаи бурычлар:
____________________________________________
_______________________________________________________________

Мәнфәгатьләр каршылыгын булдырмау яисә җайга салу буенча тәкъдим ителгән чаралар:
_______________________________________________________________

__
Гамәлдәге белдерү кәгазен тикшергәндә Татарстан Республикасы ___________ *(район иселе)* муниципаль районының Комиссия утырышында шәхсән катнашырга исәплим (исәпләмим) (кирәген сызарга).
«__» _______ 20__ ел. ________________________________________________

(белдерү кәгазен җибәргән затның имзасы) (тулы имзасы)

Кушымта №2
вазифаи бурычларны башкарганда мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең хәбәр итү Тәртибенә

**Мәнфәгатьләр каршылыгына китергән яки китерү куркынычы туганда, шәхси кызыксыну килеп чыгуы турында Татарстан Республикасы __________ *(район иселе)* муниципаль районының җирле үзидарә органы ведомствосына караган оешма (учреждение) җитәкчесенең эш бирүче (эш бирүченең вәкиле) белдерү кәгазьләрен теркәү**
**Журналы**

| N п/п | Белдерү кәгазенең теркәлү саны | Белдерү кәгазенең теркәлү датасы | Белдерү кәгазе тапшырылган | | Белдерү кәгазе теркәлгән | | | Белдерү кәгазе күчермәсен алу турында билге (алдым, имза) яисә күчермәне почта аша җибәрү турында билге |
|---|---|---|---|---|---|---|---|---|
| | | | Ф.И.О. | вазифасы | Ф.И.О. | вазифасы | имза | |
| 1 | 2 | 3 | 4 | 5 | 6 | 7 | 8 | 9 |
| | | | | | | | | |

________________________________________